КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1287

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карарына 3 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 июнь, 497 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 3 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымта исемендә «структур бүлекчәләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

искәрмәдә «III төркем – Әлмәт, Зеленодольск, Түбән Кама муниципаль районнары» сүзләрен «III төркем – Әлмәт, Зеленодольск, Түбән Кама муниципаль районнары, административ үзәкләре шәһәр округларында урнашкан муниципаль районнар.» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн үткәч үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин